## Дәреснең темасы:
# «Хәл һәм аның төрләре. Урын хәле.»

**Максат:** *укучыларның күзәтүчәлекләрен, фикерләү, чагыштыра белү сәләтләрен, сөйләм телләрен үстерү.*


**Бурычлар:**

*1. Җөмлә кисәкләре турында өйрәнгәннәрне искә төшерү.*

*2. Укучыларга хәлләр, хәлләрнең бирелешен аңлату, аларның төркемчәләргә бүленешен ачыклау.*

*3. Урын хәле. Укучыларга урын хәлен таба һәм аларга хас үзенчәлекләрне таный белергә өйрәнү өчен ярдәм итү.*

# Җөмлә кисәкләренең шәҗәрә агачы.



# Хәлләр гаиләсе.

1. Балаларым! Басуыбыз эчендә бер хәзинә бар. Әмма кай җиренә күмелгән икәнен белә алмадым. *(Дәрдемәнд)*

*2.Хәзер миңа элеккегә караганда да иртәрәк торырга туры килә. (А.Алиш)*

*3.Алдымда ак кар җәелгән ялтырап, ап-ак булып,*
*Энҗе-мәрҗәннәр чәчелгән өстенә вак-вак булып. (Ш. Бабич)*

*4. Ләкин бу биш-алты сәгать миңа күз ачып йому кадәрле дә тоелмады. (Г. Ибраһимов)*

*5. Агачлардан җанга ятыш әйбер ясар өчен, ничәмә ничә корал кулланалар. (Ф.Яруллин)*

*6.Ял итәргә, тамакны туйдырыга туктаган идек. (Г.Әпсәләмов)*

*7. Җиргә бассам арта егәрлегем,*
*Күккә баксам, иркен тын алам. (Э. Мөэминова)*

*8.Көн кичкә авышсада, үзенә күрә матурланып китте. (Х.Хәйруллин)*



Хәл һәм аның төрләре.


# Урын хәле.


# Урын хәлендә кунакта.

- Эш яки хәлнең урынын белдереп, кайда? кая? кайдан? сорауларының берсенә җавап була торган хәл урын хәле була.


# Рәсемнәр буенча җөмләләр төзергә. Анда урын хәлләре кертелергә тиеш.









**Җөмләләрдән чыгып хәлләрнең үзенчәлекләрен ачыклыйк.**

| т/с | Мисал өчен җөмләләр. | Соравы | Эш яки хәлне кайсы яктан ачыклый? | Ничек белдерелә? |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Кошлар, никтер түбәнтен очалар. | | | |
| 2 | Урманда кошларга игътибарлы бул! | | | |
| 3 | Торналар көньякка китә башладылар. | | | |
| 4 | Машиналар кырдан ашлык ташыйлар. | | | |
| 5 | Батыр диңгезчеләр маякка таба юл тоттылар. | | | |

# Нәтиҗә.

- Урын хәле юнәлеш, чыгыш,урын-вакыт килешендәге исемнәр, урын рәвеше, шулай ук бәйлек (бәйлек сүз) белән килгән исемнәр ярдәмендә белдерелә.

# Тест.

**А. Татар телендә ничә җөмлә кисәге бар?**

1. 4 җөмлә кисәге бар.
2. 5 җөмлә кисәге бар.
3. 6 җөмлә кисәге бар.
4. 7 җөмлә кисәге бар.

**Б. Хәлләр ничә төргә бүленә?**

1. 5 төргә бүленә.
2. 9 төргә бүленә.
3. 8 төргә бүленә.
4. 12 төргә бүленә.

**В**. *Юк, **аңа** тапшыра алмадым, «Ялкын» редакциясендә калдырдым.* **Калын хәре белән бирелгән сүз нинди җөмлә кисәге?**

1. Урын хәле**.**
2. Тәмамлык.
3. Аергыч.
4. Ия.

**Г. Урын хәле сораулары:**

1. Кайда? Кайчан?
2. Күпме? Кая? Кайдан?
3. Кайда? Кая? Кайдан?
4. Кая? Ничек? Нигә

**Д. Урын хәлләре нинди сүз төркемнәре ярдәмендәбелдерелә?**

**1.** Бары тик исемнәр белән генә.
2. Юнәлеш, чыгыш һәм урын-вакыт килешендәге исемнәр, урын рәвеше, шулай ук бәйлек (бәйлек сүз) белән
3. Урын рәвеше белән генә.
4. Юнәлеш, чыгыш һәм урын-вакыт килешендәге исемнәр белән генә.